

Сугышнын барлык авырлыкларын vз жилкәсендә татыган, олы тормыш юлы vткән Кадошкино районы Латышовка авылы тыл хезмәтчәннәре Боек Жинvнен 80-еллыгын бәйрәм итv алдыннан хәтер сандыгындагы истәлекләре белән уртаклаштылар.
Бvген алар ул фажигале коннәрнен сонгы шаһитлары. Истәлекләр аларны олылар белән беррәттән кырда эшләгән, фронтка посылка жибәргән, авыр хезмәт белән Жинvне якынайткан коточкыч елларга кvчерде.      Бvгенге Латышовка урта мәктәбе укучылары шул чор балалары арасындагы диалог бик кvнелгә vтеп керерлек һәм кvнелгә ятышлы булып чыкты. Бvләк йозеннән, торле сыйныф укучылары коче белән әзерләнгән ижади номерлар бvләк иткәннәр.
Чарага Боек Ватан сугышы чоры балалары Алий Абейдулла улы Бикмаев белән Сания Искак кызы Байчурина чакырылган иде. Очрашу жылы, дустанә атмосферада узган. Кунаклар балалар белән vзләренен балачак хатирәләре белән уртаклашканнар, сугыштан сонгы авыр елларда олкәннәр белән беррәттән кырда ничек эшләvләре турында сойләгәннәр. Кочләреннән килгәнчә Жинv конен якынайтканнар очрашуда катнашучы тыл һәм хезмәт ветераннары. Балачаклары сугыш чорына туры килгән әлеге тырыш, булдык-лы, кешелекле, авырлыклар алдында каушап калмый торган олы йорәкле, кин кvнелле, сабыр һәм шул ук вакытта гади һәм тыйнак Сания Искак кызы Байчурина белән Алий Абейдулла улы Бикмаев.
Яшь буын сугыш турында, сугыш чоры балаларынын язмышы турында кvбрәк белергә теләп, кvп сораулар биргәннәр. Әнгәмә ачык һәм ихлас vткән. Сания Искак кызы белән Алий Абейдулла улы сойләгән истәлекләре барысынын да кvнелләрен нечкәрткән: шулкадәр кvп авырлыклар кичерсәләр дә энергияләре һәм тормыш соючәнлекләре сокландыра - кочле рухлылар алар!
Чара азагында фатиха сvзләре белән Латышовка авылы мәчете имамы Камиль Халил улы Ахметов чыгыш ясаган.
Авыл мәдәният vзәге житәкчесе Надия Мансур кызы Байчурина тыл хезмәтчәннәренен һәм сугыш чоры балаларынын фронтка ярдәме, колхозчыларнын сугыш елларындагы хезмәт унышлары турында сойләгәннәре һәм бу чарада катнашулары, бик кызыклы хикәяләре очен рәхмәт белдергән.
Бvләк итеп тәрбия буенча Латышовка урта мәктәбе директоры кинәшчесе Галина

Петровна Вяльшина житәкчелегендә укучылар белән авыл vзешчәннәре ижат номерлары әзерләгәннәр, шулай ук хормәт йозенннән тыл хезмәтчәннәренә кечкенә бvләкләр дә тапшырганнар.
Истәлекле очрашу бергәләп фотога тоштv белән тәмамлана. Очрашуда ишетелгәннәр эзсез vтмәячәк, балаларнын яшь йорәкләрендә мәнгегә калачак. Әгәр без хәзер яшьләрне тәрбияләv турында кайгыртсак, безнен киләчәгебез ышанычлы кулларда булуына ышаныч зур.



Тагы бер очрашу. Рузаевка районы Татар Пешлә авылында гомер итvче 89 яшен тутырган тыл һәм хезмәт ветераны Сания Али кызы Саляева йортында авылнын урта мәктәбе 9нчы сыйныф укучылары булдылар.
Сания әби авыр Боек Ватан сугышы еллары турындагы хатирәләре белән кунаклар белән уртаклашты.
Сания Али кызы хәтеренә уелып калган ин авыр чакларны житкерде: укучыларга анын гаиләсе сугыш вакы-тындагы ачлыктан интеккән халыкка ярдәм иткәне турында мавыктыргыч итеп сойләде. Тагы Боек Ватан сугышы елларында авыл халкы даими куркыныч астында яшәгән, бигрәк тә авыл остен-нән фашист самолетлары очканда. Кешеләр, ут дошманнарнын игътибарын жәлеп итмәсен очен, тәрәзәләрне ябарга тырышканнар, ә балалар, алар арасында кечкенә Сания да булган, бомбага тотудан куркып, остәл астына яшеренvләре турында да кино лентасы караганнар итеп сойләп биргән.
- Утызынчы елларда Али әтием репрессияләнә, ә Мәйсәрә әнием колхознын тавыклар фермасында эшли була. Менә алар кvпне кvргән кешеләр. Халыкка бик авыр булды. Ул коннәрне бvтән кvрергә язмасын. Кvкләребез тыныч, имин булсын! – дип кичерешләре белән уртаклашты язма героебыз.
Укучылар зур игътибар белән Сания Али кызынын тарихларын тынлаганнар, бу хәтердә уелып калырлык истәлекләр булган, укучылар мавыгып бер-бер артлы сораулар да биргәннәр. Сонынннан бергәләшеп тәмлушкалар белән чәй эчкәннәр һәм тагы да игътибар белән Сания әбиләренен vткәннәрен тынлаганнар.
Очрашу балалар очен кvнелле сюрприз белән тәмамланган: Сания Алиевна кунакка килгән укучыларнын барысын да шоколадлар белән дә сыйлаган. Киткәндә, балалар vт-кәргән вакытларына рәхмәт бел-дереп, рәхәт тулы кvнелләр белән саубуллашканнар.
Мондый очрашулар яшь буынга vз иленен тарихын яхшырак анларга һәм ата-бабаларынын батырлыклары турында хәтерне сакларга ярдәм итә.

**Наилә НАСЫРОВА**